ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

18 ноябрь 2024ел № 7653

Башкарма комитетның 2023 елның 22 декабрендәге 12414 номерлы Карары белән расланган Башкарма комитетның үз компетенциясе чикләрендә административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзүгә вәкаләтле вазыйфаи затлары исемлегенә үзгәрешләр кертү хакында

Шәһәр Советының 2007 елның 21 февралендәге 19/8 номерлы Карары белән расланган Муниципаль хокукый актлар системасы турында нигезләмәнең 5.24, 5.25 пунктлары нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Башкарма комитетның 2023 елның 22 декабрендәге 12414 номерлы Карары белән (Башкарма комитетның 2024 елның 22 мартындагы 1786 номерлы Карары редакциясендә) расланган Башкарма комитетның үз компетенциясе чикләрендә административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзүгә вәкаләтле вазыйфаи затлары исемлегенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 1 пунктта:

- «3.3, 3.4, 3.6 статьяларында» сүзләреннән соң «3.15.1» цифрларын өстәргә;
- түбәндәге эчтәлектәге алтынчы абзац өстәргә:

«- территориядәге оешмалар белән үзара эшчәнлек бүлегенең 1 категорияле* белгече.»;

2) 2 пунктта «3.15» цифрларыннан соң «3.15.1» цифрларын өстәргә.

2. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны рәсми бастырып чыгаруны һәм аны «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://pravo.tatarstan.ru), Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитетның Автозавод районы хакимияте Башлыгы вазыйфаларын башкаручы А.Ш. Хөснуллинга, Башкарма комитетның Комсомол районы хакимияте Башлыгы Л.И. Әхмәтҗановка, Башкарма комитетның Үзәк районы хакимияте Башлыгы вазыйфаларын башкаручы А.Ж. Рәҗәповка йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Ф.Ш. Салахов